**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет Татарско-Шуганского сельского поселения Азнакаевского муниципального района

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге башкарма комитеты

423327, Республика Татарстан, Азнакаевский муниципальный район, с.Татарский Шуган, ул. Советская, д. 41в

Совет урамы, 41в, Татар Шуганы авылы, Азнакай муниципаль районы, 423327

Тел. (факс) (85592) 36-1-41 Tshug .Azn @tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15 март 2021 ел №7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татар Шуганы авыл җирлеге» территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыю турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 2020 елның 12 маендагы № 13-20р күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә халыкның күпләп ял итүе һәм суда коткару чаралары өчен җиһазландырылган урыннар булмау сәбәпле, су объектларының һәм елгаларының санитария-гигиена нормаларына туры килмәве, елгаларда һәм сулыкларда бәхетсезлек очракларының иминлеген тәэмин итү, кисәтү һәм санын киметү максатыннан Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыярга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан «Татар Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең барлык милек рәвешләрендәге предприятие, оешма, учреждениеләр җитәкчеләренә су объектларында су коенуны тыю турындагы әлеге карар белән танышуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитетына су объектлары янында су коенуны тыю турындагы мәгълүмат белән кисәтү аншлаглары урнаштырырга.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб -адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының мәгълүмат сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

Башлык М.Ш.Хәертдинов